- чүп-чар кабул итү камераларын, контейнерлар (бункерлар) һәм контейнер мәйданчыкларын җыештыру, юу һәм дезинфекцияләү;
- яңгыр һәм кар суларын читкә чыгару;
-каты көнкүреш, зур габаритлы һәм башка калдыкларны җыю һәм чыгару;
- тузаннан арындыру һәм һава чистарту өчен территориягә су сибү;

- яшел үсентеләрнең сакланышын тәэмин итү, аларны карап тору; территорияләрдә гражданнар тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затлар милке өчен куркыныч булган коры-сары һәм яшел үсентеләрне вакытында кисү, Сосновский балтырганын юк итү, бетерү буенча кешегә зыян салмаслык чаралар үткәрү (химик, механик һәм башкалар).

Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар аңа чәчәк ата башлаганчы гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү, чабу, үсү урыннарын казу, корыганнарын юкка чыгару, тамырын казып чыгару, туфракны эшкәртеп, күпьеллык үлән чәчү юлы белән үткәрелә;

- коммуналь объектлар, инженерлык коммуникацияләре (корылмалар), юллар, тимер юллар, күперләр, җәяүлеләр кичүе, реставрация, археологик һәм башка җир эшләре алып барылганнан соң бозылган элементларны яңадан торгызу;

- күзәтү һәм яңгыр сулары коеларын (яңгыр канализациясен), җир асты коммуникацияләре коеларын (корылмаларын) гамәлдәге дәүләт стандартлары таләпләре нигезендә карап тоту;

- җир кишәрлекләре киртәләрен карап тоту, шул исәптән анда урнашкан җимерелгән (сүтелгән) биналарның, корылмаларның территориягә чит затлар үтеп кереп рөхсәтсез урыннарда чүп-чар ташлау мөмкинлеге бирми торган коймаларын карап тоту, шулай ук аларны пычрактан, кардан һәм мәгълүмати-басма продукциядән вакытында чистартуны тәэмин итү.

Юлларны карап тоту

36. Юлларны карап тотуны тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручы) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә муниципаль контрактлар төзегән оешмалар башкара.

37. Юл территорияләрен карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге юлларны ремонтлау;

- тротуарлардан (җәяүлеләр зоналарыннан, сукмаклардан), автомобиль йөрү өлешеннән, ясалма юл корылмаларыннан пычрак, чүп-чар, кар һәм бозны чыгару, җыештыру;

- юл катламнарын юу һәм су сибү;

- газон һәм яшел үсентеләрне карау;

- җәмәгать һәм тимер юл транспортының элемтә челтәрен һәм тышкы яктырту баганаларын ремонтлау;

-кече архитектура формаларын ремонтлау һәм буяу;

- күзәтү һәм яңгыр сулары коеларын, канауларны һәм ясалма юл корылмалары составына керүче ачык лотларны урнаштыру, ремонтлау һәм чистарту;

- коймалар, турникетлар, кече архитектура формаларының киртәләрен урнаштыру, ремонтлау һәм ел саен буяу.

38. Юл катламнарын саклау максатларында рөхсәт ителми:

- йөкне сөйрәп ташу;

- төяү-бушату эшләре вакытында рельслар, бүрәнәләр, тимер балкалар, торбалар, кирпеч, башка авыр предметлар ташлау һәм саклау;

- машиналар йөрү юлына һәм тротуарларга төзелеш материалларын һәм төзелеш калдыклары ташлау.

39.Юлларны төзекләндерүнең аерым элементларына таләпләр:

- җәяүлеләр юлындагыюнәлеш бирүче  металл коймаларны һәм тротуар баганаларын сезонлы буяу ел саен кышкы сезон тәмамланганнан соң, төзекләндерү айлыгы үткәрү чорында гамәлгә ашырыла. Буяу алдыннан коймалар ремонтланырга, пычрактан чистартылырга тиеш;
-барлык юл тамгасы заказчы тарафыннан билгеләнгән вакыт һәм чират тәртибендә юл тамгасы төшерү өчен расланган паспортлар (схемалар) нигезендә үтәлергә тиеш;
- юллар тамгасы таләп ителә торган төс һәм яктылык-техник характеристикаларына , эләктерү коэффициентына җавап бирергә, эксплуатацияләү  чорында  бөтен мәйдан буенча сакланырга тиеш;
-юл билгеләрен ныгытуның конструкцияләре һәм системалары кую шартларына һәм монтажлау мөмкинлекләренә карап сайлап алына;
- юл билгеләре төзек хәлдә булырга, вакытында чистартылырга һәм юылырга тиеш.
Вакытлыча билгеләнгән юл билгеләре сәбәпләрен бетергәннән соң бер тәүлек эчендә алына.
- коммуникация системасының  кору элементлары: транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте юнәлешләрен күрсәткечләр, җирлекнең планлаштыру-структур элементларын күрсәткечләр юлларда һәм транспорт чишелешләрендә аларга хәрәкәт юнәлешен күрсәтү өчен билгеләнә.

Муниципаль берәмлекнең гомуми файдалану территорияләрен карап тоту һәм төзекләндерү

40. Муниципаль берәмлекнең гомуми файдалану территорияләрендә тыела:
1) территорияне металл, төзелеш һәм авыл хуҗалыгы продукциясе һәм калдыклары, ягулык-майлау материаллары, нефть продуктлары белән пычрату, чүп-чар ташлау урыннары ясау;
2) калдыклар һәм чүп-чарны махсус билгеләнгән урыннардагы контейнерлардан тыш җирләргә ташлау;
3) стационар булмаган сәүдә объектларын, шулай ук ял итү өлкәсендәге хезмәт күрсәтү объектларын (аттракционнар, кабартылган батутлар, велосипедлар прокаты, роликлар һәм халыкның ялын һәм күңел ачуын оештыру өчен файдаланыла торган башка шундый объектларны) билгеләнгән тәртипне бозып урнаштыру;
4) автомототранспорт чараларын махсус билгеләнгән урыннардан тыш җирләрдә юу һәм чистарту;
5) сибелүчән, тузанлы  йөкләрне, яфрак, төрле эретмәләрне юлларны пычранудан саклаучы, махсус җиһазландырылмаган, брезент яки башка материал белән капланмаган йөк машиналарында ташу;
6) стационар булмаган объектларны  үзирекле урнаштыру;
7) җир эшләрен тиешле рөхсәттән (ордер) башка башкару;
8) грунтны, чүп-чарны, калдыкларны, карны, бозны тиешсез урыннарга ташлау;
9) гамәлдәге законнарны бозып квартал эчендәге юлларга һәм йортларга керү юлларына, урамнарга, тротуарларга, газоннарга төзелеш материаллары ташлау;
10) кәгазьләрне, чүп-чарны, тәмәке төпчекләрен мәйданчыклар, ишегаллары, паркларда, скверларда һәм башка җәмәгать урыннарында  газоннарга, тротуарларга, урам территорияләренә ташлау;
11) бакча утыргычларының аркаларына менеп утырырга,эскәмияләрне, урамнарны яктырту фонарьларын, башка кече архитектура формаларын вату, пычрату;
12) яңгыр сулары канализациясенең, кюветның рәшәткәләренә, коеларның япкычларына көнкүреш калдыклары ташлау;

13) предприятиеләрнең эчке территорияләрендә һәм шәхси йорт яннарында чүп-чар, яфраклар һәм коры үлән, җитештерү калдыклары, каты коммуналь калдыкларны янгынга каршы чаралар(ябык савытлар һәм янгын сүндерү чаралары) күрмичә яндыру;

14) фасадларны үз белдеге белән үзгәртеп кору, арендада яки милектә булган җир кишәрлекләреннән читтә барлык типтагы гаражлар, базлар, утын сарайлары, будкалар, күгәрчен оялары,теплицалар, тирес җыю урыннары һәм башка корылмалар урнаштыру, шулай ук билгеләнмәгән урыннарда кече архитектура формалары кую, тышкы мәгүлумат урнаштыру;

15) Яшел үсентеләрне сындыру, юк итү, аларга атынгычлар, гамаклар элү, кәүсәләрен каезлау;

16) газоннарны бозу һәм юк итү;

17) гамәлдәге законнарны бозып, юлның машиналар йөрү өлешенә кар бушату;

18) йорт хайваннары, кошларның гамәлдәге законнарны бозып авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләгән җирләрдән (көтүлекләрдән) тыш җирләрдә, хуҗасыз рәвештә урамда, авыл хуҗалыгы җирләрендә йөрүе ;

19) эре габаритлы төзелеш чүп-чарын, ватык көнкүреш техникасы һәм җиһазларын, киселгән агачларны килешү кәгазе булмаган килеш һәм гамәлдәге законнарны бозып, контейнер мәйданчыкларына ташлау;

20) гамәлдәге законнарны бозып төзек булмаган транспорт чарасын урнаштыру һәм саклау;

21) керне, автотранспорт чараларын, хайваннарны чишмәләр, кое, су колонкалары, елга ярларында, күлләрдә һәм ясалма (декоратив) сулыклар буенда юу;

22)тиресне йорт яны кишәрлегеннән читтә торак йорт буена урнаштыру;

23) йорт яны территорияләрендә, урамнарда һәм бу максатлар өчен билгеләнмәгән башка урыннарда юынтык сулар түгү, чүп-чар ташлау урыннары ясау. Канализацияләре булмаган торак биналарда үз калдыкларын җыю өчен эре предметлар эләгә алмаслык итеп ясалган рәшәткәле япкычлы чокырлар карала;

24) йөк төяү - бушату эшләре алып барганда йөкне сөйрәп ташу, рельслар, бүрәнәләр, тимер балкалар, торбалар, кирпеч һәм башка авыр предметларны юл өслегенә ташлау, чылбырлы йөрешле машиналарга каты өслекле урамнар буйлап узып китү, квартал юллары эчендә зур йөк транспорты хәрәкәте;

25) торак пункт территориясенә автотранспорт тәгәрмәчләреннән балчык коелу;

26) транспорт чараларын торак пунктлар чикләренә (газоннарны, чәчәк түтәлләрен һәм үләннәр белән шөгыльләнүче башка территорияләрне дә кертеп), балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларына кую.

Шәхси торак йортларны һәм территорияне төзекләндерү

41. Хосусый торак йорт милекчеләре (яки) яллаучылар (алга таба - торак йортлар хуҗалары), әгәр законда яки килешүдә башкасы каралмаган булса,түбәндәгеләрне гамәлгә ашыралар:

- торак йортларның фасадларының, коймаларның, шулай ук йорт салу чикләрендә башка корылмаларның тиешле торышы, аларны вакытында ремонтлау һәм буяу;
- торак йортта тиешле номер билгесе булу;
- йорт территориясен тәртиптә тоту һәм тиешле санитар хәлдә тотуны тәэмин итү;

- йорт салу чикләрендә яшел үсентеләрне тәртиптә тоту, куаклар һәм агачларны санитар кисү, газүткәргечләрнең сак зонасында, кабель һәм һава электр тапшыру линияләрендә һәм башка инженерлык челтәрләрендә агачлар утыртуга юл куймау;
- канауларны һәм су торбаларын чистарту, язгы чорда кар суы агуны тәэмин итү;
- бирелгән җир участогы чикләрендә, үзәкләштерелгән канализация булмаганда, юынтык су чокыры, бәдрәфне санитар нормалар нигезендә даими рәвештә чистартып тору һәм дезинфекция ясау;
- каты һәм зур габаритлы калдыкларны махсус мәйданчыкларда урнаштырылган контейнерларга туплау;
- билгеләнгән тәртип нигезендә каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны вакытында җыю һәм чыгару.

42. Шәхси торак төзелеше территориясендә рөхсәт ителми:
- чүп үләннәре үстерү, яфракларны, территорияләрдәге һәм йорт биләмәләрендәге теләсә нинди калдыкларны һәм чүп-чарны яндыру;
- йорт яны территориясен теләсә нинди калдыклар белән чүпләү;
- коймаларны йорт биләмәләре чигеннән чыгарып урнаштыру;
- йорт биләмәләрендә һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә яфракларны, теләсә нинди калдыкларны һәм чүп-чарны яндыру;
- йорт биләмәсеннән читтә күмер, утын, зур габарит калдыклар, төзелеш материаллары саклау;
- йорт биләмәләре чигеннән соң ишегалды корылмалары, чүп чокырлары төзү;
- урам юлларында махсус транспорт һәм урып-җыю техникасының үтемлелеген кыенлаштыра торган каршылыклар булдыру;
- территорияне төзекләндерү элементларын җимерергә һәм бозу, сулыкларны чүпләү;
- йорт биләмәләрендә төзек булмаган транспорт чарасын саклау;
- якын-тирә территорияне теләсә нинди калдыклар белән чүпләү;
- юынтык су түгү җайланмаларын, сыек калдыкларны машиналар йөрү юлына урнаштыру.

Индивидуаль торак йорт яки хуҗалык корылмалары төзү милекче тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта, йорт янындагы территориядә, шул исәптән урамда, Ташкичү җирлегенең башкарма комитетының язма рөхсәте булган очракта, төзелеш материалларын вакытлыча саклау бер айга рөхсәт ителә. Төзелеш материаллары кеше тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерүне, шулай ук җимерелү, төшү яки башка йогынты нәтиҗәсендә өченче затларның милкенә зыян китерүне булдырмый кала торган ысул белән урнаштырылган булырга тиеш. Шул ук вакытта автотранспорт үтә алу тәэмин ителергә тиеш.

Яңгыр сулары канализациясе челтәрләре, күзәтү һәм яңгыр сулары коесы, су агызу корылмаларын карап тоту

43. Күзәтү һәм яңгыр сулары коесы, җир асты коммуникацияләре коелары, люклар (рәшәткәләр) ябык хәлдә булырга һәм транспорт һәм җәяүлеләрнең куркынычсыз хәрәкәтен тәэмин итәрлек төзек хәлдә булырга тиеш.

44. Күзәтү һәм яңгыр сулары коесын карап тору, чистарту, төзек хәлдә тотуны гамәлдәге дәүләт стандартлары буенча аларның милекчеләре башкара.

45. Җирлектә яңгыр канализациясенең магистраль һәм квартал эчендәге челтәрләрен карап тоту һәм эксплуатацияләү авыл җирлеге бюджетында каралган акчалар чикләрендә махсуслаштырылган оешмалар белән төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Яңгыр канализациясенең ведомство челтәрләрен карап тоту һәм эксплуатацияләү тиешле оешмалар хисабына башкарыла.

Хуҗасыз инженерлык коммуникацияләре һәм күзәтү коелары юлларны карап тотуны гамәлгә ашыручы махсус оешмалар тарафыннан тиешенчә куркынычсыз хәлдә сакланырга тиеш.

46. Яңгыр сулары канализациясе коллекторларының сакланышы максатыннан, коллектор күчәреннән һәр якка 2 м ераклыкта сак зонасы урнаштырыла .

47. Тиешле документларны рәсмиләштермәгән очракта эксплуатацияләүче оешма белән язмача килешү булмаганда яңгыр канализациясе коллекторларының сак зонасы чикләрендә гамәлдәге законда билгеләнгән очракларда рөхсәт ителми:

- җир эшләре башкару;
- яңгыр сулары канализациясе челтәрләрен зарарлау, су кабул итү люкларын томалау яки җимерү;
- сәүдә, хуҗалык һәм көнкүреш корылмалары төзү, урнаштыру;
- сәнәгать, көнкүреш калдыкларын, чүп-чар һәм башка материаллар ташлау.

48.Канализация, яңгыр сулары җайланмалары, системалары, челтәрләре һәм корылмалары төзек булмау аркасында урамнарны, биналарны, корылмаларны су басу, шулай ук газоннарга, тротуарларга, урамнарга һәм ишегалды территорияләренә су агызу.

49. Авыл җирлеге территориясендә су йоту коелары һәм пар чыгару мәйданчыклары урнаштыру рөхсәт ителми.

50. Яңгыр коеларының рәшәткәләре даими рәвештә чистартылган хәлдә булырга тиеш. Рәшәткәләр һәм коеларны чүпләү, су бастыру рөхсәт ителми. Яңгыр канализациясен һәм яңгыр коеларын профилактик тикшерү һәм аларны чистарту елына ике тапкырдан да ким башкарылмаска тиеш. Күзәтү һәм яңгыр коеларын чистартканнан соң, чыгарылган барлык калдык төрләре кичекмәстән ташланырга тиеш.

51. Карау коеларның люклары машиналар йөрү юллары, тротуарлар, җәяүлеләр һәм велосипед юллары, яшел зоналар белән бер биеклектә булырга тиеш.

Машиналар йөрү өлешендә, тротуарлар, җәяүлеләр һәм велосипед юллары, яшел зоналар белән коелар биеклеге аермасы 2 см.дан артык, яңгыр сулары җыя торган коеларныкы 3 см дан артык булу рөхсәт ителә.

52. Япкычлары яки рәшәткәләре җимерелгән яки юкка чыгарылган коелар булган очракта, алар кичекмәстән челтәрдән файдаланучы оешма тарафыннан алдан кисәтүче билгеләр белән билгеләнергә һәм билгеләнгән вакытка алыштырылырга тиеш.

53. Инженерлык челтәрләрендә планлы эшләр вакытында канализация сулары канализация челтәренең якындагы коесына, су һәм җылылык челтәрләреннән яңгыр канализациясенә (булган очракта) чыгарыла. Суны юлга чыгару тыела.

Су агу нәтиҗәләрен бетерү зыян күргән инженер челтәрләренең хуҗалары хисабына башкарыла.

54. Яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең техник торышы (шул исәптән люкларны, рәшәткаларны вакытында ябу) өчен җаваплылык эксплуатацияүче оешмаларга йөкләнә.

Техник элемтә чараларын карап тоту

55. Биналарны инженер-техник тәэмин итү өчен билгеләнгән кабельле элемтә, телевидение, радио, интернет һәм башка шундый челтәрләрне урнаштыру җир асты юлы белән башкарыла (траншеяларда, каналларда, тоннельләрдә).

56. Биналарга тышкы коммуникацияләрне башка ысул белән (һава, җир өсте) урнаштыру, эксплуатацияләүче оешмаларның тиешле техник шартларын үтәү шарты белән, аларны җир астында урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта гына рөхсәт ителә.

57. Асылмалы элемтә линияләрен һәм һава-кабель юлларын беркетү сыйфатында түбәндәгеләрне файдаланырга ярамый:

- автомобиль юлларын төзекләндерү элементлары: юл киртәләре, светофорлар, юл билгеләре урнаштыру өчен билгеләнгән элементлар һәм конструкцияләр;

- фасадлар, түбәләр, бина стеналары (төтен чыга торган урыннар, вентиляция, телевидение һәм радионы күмәк кабул итү системасы антенналары, фронтоннар, козырекалар, ишекләр, тәрәзәләр).

58. Рөхсәт ителми:

- бер бинадан икенчесенә һава юлы белән элемтә кабельләре салганда юллар кисешү;

- бүлгеч муфт шкафыннан тыш кабель запасларын урнаштыру;

59. Милекчеләр (хуҗалары) техник элемтә чаралары (кабельләр, кабельләрне беркетү элементлары, бүлү һәм муфт шкафлары һәм башкалар), шулай ук алар ярдәмендә тиешле хәлдә тоташтырыла торган техник җайланмаларны (изоляция тышчасы булмау, буялмаган булу, коррозия һәм/яки механик җәрәхәтләр булу, чыбыклар яктырту баганаларына һәм электр тапшыру линияләренә тоташтыру рөхсәт ителми) тиешле дәрәҗәдә тотарга тиеш.

Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту

60. Тышкы яктырту элементларына яктырткычлар, кронштейннар, терәкләр, чыбыклар, кабельләр, туклану чыганаклары (шул исәптән җыю, туклану пунктлары, идарә тартмалары) керә.

61. Урамнар, юллар, тротуарлар, торак кварталлар, ишегаллары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар территорияләре, шулай ук аншлаглар һәм җәмәгать һәм торак биналарының номер билгеләре, юл билгеләре һәм күрсәткечләр, җирлек мәгълүматы элементлары һәм витриналар тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылырга тиеш.

62. Биналарның һәм корылмаларның милекчеләре, төрле милек формасына карамастан, проект буенча биналарның һәм корылмаларның архитектур-нәфис яктыртылуын һәм яктыткычларның эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

63. Төп мәйданнарда, магистральләрдә һәм урамнарда, транспорт тоннельләрендә янмый торган яктырткычларның саны 3% тан артмаска тиеш, башка җирлек территорияләрендә (район әһәмиятендәге урамнар, ишегалды территорияләре) - 5%, җир асты җәяүлеләр кичүләрендә төнлә һәм көндезге режимнарда - 10% тан артмаска тиеш (10 яктырткычның 1 се эшләмәскә мөмкин).

64.Терекөмешле сафтан чыккан газ лампалары бу максатлар өчен махсус билгеләнгән биналарда сакланырга һәм утильләштерү өчен махсус предприятиеләргә чыгарылырга тиеш. Әлеге төр лампаларны җирлек чүплекләренә, чүп-чар эшкәртү заводларына ташларга ярамый.

65. Тышкы яктырту җайланмаларының металл баганалары, кронштейн һәм башка элементлары чиста булырга тиеш, коррозия элементлары, авышу булмаска һәм милекчеләр тарафыннан буялган булырга тиеш.

66. Тышкы яктыртуның бердәм системасына тоташтырылган юл, урам һәм йорт яны яктырткычларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә муниципаль контракт төзегән вәкаләтле орган яки оешма башкара.

Торак йортларны тапшыру бүлгечләренә тоташтырган йорт яны утларын карап тотуны һәм ремонтлауны идарәче оешмалар башкара.

67. Тышкы яктырту баганалары, җәмәгать (тимер юл) транспортының элемтә челтәре баганалары, саклагыч, бүлү киртәләре, юл корылмалары һәм җиһаз элементлары буялырга, язулардан һәм теләсә кайсы мәгълүмати-басма продукциядән чистартылырга, төзек хәлдә һәм чиста булырга тиеш.

68. Тышкы яктырту баганаларын, җәмәгать (тимер юл) транспортының элемтә челтәре баганасын алыштырганда бу конструкцияләр сүтелергә һәм челтәр хуҗалары тарафыннан өч тәүлек эчендә чыгарылган булырга тиеш.

Тышкы яктырту баганалары милекче тарафыннан мондый ихтыяҗ (сүтү) булган вакыттан соң 1 тәүлек эчендә чыгарыла.

69. Җәмәгать (тимер юл) транспортының элемтә баганаларында һәм таянычларында урнаштырылган барлык элементларның һәм объектларның төзек һәм имин торышы һәм төзек тышкы кыяфәте өчен әлеге таянычның милекчесе җавап бирә.

70. Үткәргечләрнең, терәкләрнең, изоляторларның элементлары зыян күргән очракта тышкы яктырту җайланмаларын файдалану рөхсәт ителми.

Электр чыбыклары өзелү белән бәйле тышкы яктырту җайланмалары эшендәге кимчелекләр ачыкланганнан соң кичекмәстән бетерелергә тиеш.

71. Челтәрләргә үткәргечләрне һәм кабельләрне үз белдеге белән тоташтыру һәм тышкы яктырту җайланмалары белән тоташтыру рөхсәт ителми.

72. Тышкы яктырту объектлары яки тышкы яктырту чаралары белән җиһазландырылган объектларның милекчеләре (хуҗалары), шулай ук тышкы яктырту объектларына (чараларына) хезмәт күрсәтүче оешмаларның бурычлары:

- урамнарны, юлларны тиешенчә яктыртуны, баганаларның һәм яктырткычларның, яктырту җайланмаларының сыйфатын күзәтеп тору, бозылган яки зыян күргән очракта вакытында ремонт ясау;
- билгеләнгән тәртип нигезендә яктырткычларны кабызуны һәм сүндерүне күзәтү;
- тышкы яктырту чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтәү;
- яктырту фонарьларын вакытында алмаштыру.

Кече архитектура формаларын карап тоту

73. Кече архитектура формаларына монументаль-декоратив бизәү элементлары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү җайланмалары, су җайланмалары, муниципаль җиһазлар, җирлек территориясендәге коммуналь-көнкүреш һәм техник җиһазлар керә.

74. Кече архитектура формаларын карап тоту бирелгән җир участоклары чикләрендә, гомуми файдалану территорияләрендә тәэмин итүче (подрядчы,

башкаручы) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә муниципаль контракт (килешү) төзегән оешма белән контракт (килешү) нигезендә җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар тарафыннан гамәлгә ашырыла.
75.Кече архитектура формалары милекчеләренең бурычлары:
- кече архитектура формаларын чиста һәм төзек хәлдә тоту;
- язгы чорда кече архитектура формаларын план нигезендә карап чыгарга, аларны иске буяудан, күгәректән арындырырга, шулай ук ватылган элементларны алыштырырга кирәк;
- кышкы чорда кече архитектура формаларын, шулай ук аларга якын килү юлларын кар һәм боздан чистарту;
-тигез өслекле комлыкларны төзекләндерү, комлыкларда елга бер тапкыр комны алыштыру;
-балалар, спорт, хуҗалык мәйданчыклары һәм ял мәйданчыклары җиһазларының ныклыгы, ышанычлылыгы һәм иминлегенең тиешле таләпләргә туры килүен күзәтеп тору;
- фонтаннар эшләгән чорда су өслеген чүп-чардан көн саен чистартып торырга кирәк.
76. Рөхсәт ителми:
- кече архитектура формаларыннан тиеш булмаганча файдалану (өлкәннәрнең балалар өчен уен мәйданчыкларында ял итүе, спорт мәйданчыкларында кием киптерү һәм башкалар.;
-теләсә нинди мәгълүмати-басма продукцияне кече архитектура формаларына ябыштырырга;
-кече архитектура формалары һәм аларның конструктив элементларын җимерергә һәм зыян китерергә;
- фонтаннарда коенырга.
Стационар булмаган объектларны карап тору
77. Стационар булмаган объектларны урнаштыру муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә мондый объектларны урнаштыру схемасы нигезендә гамәлгә ашырыла.
78. Җир кишәрлеген арендалау килешүе срогы чыккач стационар булмаган объект арендатор тарафыннан сүтелергә тиеш, ә җир участогы бушап, беренчел халәткә китерелгән булырга тиеш.
79. Стационар булмаган объектларның хуҗалары булган юридик һәм физик затларның бурычлары:
- стационар булмаган объектларны ремонтлау һәм буяу. Ремонт, проект документациясе белән билгеләнгән тәртиптә, объектның тышкы кыяфәтен саклап һәм төс үзенчәлекләрен исәпкә алып башкарылырга тиеш;
- стационар булмаган объектлар янында урналар урнаштыру, чүп савытларын кирәк булганда буяу һәм чистарту.
80. Рөхсәт ителми:
- стационар булмаган объектларга янкорма, козыреклар һәм проектлар белән каралмаган башка корылмалар төзү;
- стационар булмаган объектларянына сәүдә-суыткыч җиһазларын кую;
- стационар булмаган объектларда һәм аларның түбәләрендә товарлар, детальләр, көнкүреш һәм җитештерү характерындагы башка предметлар саклау, шулай ук стационар булмаган объектларны склад максатларында куллану.

Төзелеш эшләре башкару урыннарын карап тоту
81.Төзелеш барган мәйданнарны карап тоту, төзү һәм ремонт эшләре тәмамланганнан төзекләндерү төзүче оешмага йөкләнә.
Төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары төзелеш челтәрләре белән ябылган булырга тиеш.
82. Төзелеш башланганчы, шулай ук төзелеш яисә ремонт эшләре барганда түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:
- Башкарма комитетның хокукый актлары таләпләре нигезендә төзелеш мәйданчыгы территориясенең бөтен периметры буенча типлаштырылган коймалар урнаштыру;
- төзелеш мәйданчыгын коймасының гомуми тотрыклылыгын, ныклыгын, ышанычлылыгын, эксплуатацияләү вакытында куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- төзелеш мәйданчыгын койманың техник торышын, аның чисталыгын тикшереп тору, пычрактан, кардан, боздан, мәгълүмати-басма продукциядән һәм граффитидан вакытында чистартып тору;
- төзелеш объектының гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә җавап бирә торган мәгълүмат щитын төзелеш мәйданчыгы территориясенә кергәндә урнаштыру һәм аны тиешле хәлдә тоту;
- төзелеш мәйданчыгы периметры буенча тышкы яктыртуны тәэмин итү;
-төзелеш мәйданчыгында керү юлларын, урамнарның машиналар йөри торган өлешенә пычрак һәм чүп чыгармас өчен транспорт чараларының тәгәрмәчләрен чистарту яки юу пунктларын җиһазлау;
- төзелеш мәйданчыгы территориясендә каты көнкүреш, зур габаритлы һәм төзелеш калдыклары җыю өчен контейнерлар һәм (яки) бункерлар булуны тәэмин итү;
- төзелеш мәйданчыгыннан каты көнкүреш, зур габаритлы һәм төзелеш калдыкларын билгеләнгән тәртиптә чыгаруны оештыруны тәэмин итү;
- төзелеш мәйданчыгы территориясеннән карны килештерелгән тиешле тәртиптә махсус билгеләнгән урыннарга чыгаруны тәэмин итү;
- эш башкарганда гамәлдәге җир асты инженер коммуникацияләрен, тышкы яктырту челтәрләрен, яшеллекне һәм кече архитектура формаларын саклауны тәэмин итү.
83. Төзелеш материаллары, җиһазлары, автотранспорт һәм күчмә механизмнар, ярдәмче биналар, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең вакытлыча урнашу өчен көнкүреш вагоннары, төзелеш калдыкларының транспорт партияләрен вакытлыча саклау һәм туплау урыннары төзелеш мәйданнары чикләрендә төзелеш оешмасы проекты нигезендә урнаштырыла.
84. Рөхсәт ителми:
-гражданнарның шәхси һәм иҗтимагый иминлеген тәэмин итүгә бәйле коткару, авария-торгызу һәм башка кичектергесез эшләрдән тыш, 23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр төзелеш, ремонт, йөк төяү-бушату һәм башка эшләрне оештыру һәм үткәрү;
-Башкарма комитетның тиешле рөхсәте (күрсәтмәләре) булмаганда юллар һәм тротуарларны тарайту яисә ябу;
-чүпне яндыру һәм төзелеш производствосы калдыкларын утильләштерү.
Җирләү урыннарын карап тоту
85. Этик, санитар һәм экологик таләпләр нигезендә бирелгән җирләү урыннарын карап тоту федераль законнар һәм муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

86. Җирләү урыннарын санитар карап тотуны тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) билгеләү нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрен үткәрүгә муниципаль контракт төзегән махсуслаштырылган оешма башкара.
87.Җирләү урыннарын карап тотуга таләпләр:
- зиратларда җәмәгать бәдрәфләре чиста һәм төзек булырга тиеш. Җәмәгать бәдрәфләре янындагы урналар чистартылырга тиеш;
- зират территориясендә калдыклар һәм чүп савытлары өчен контейнерлар чистартылырга тиеш. Калдыклар җыелган саен кимендә 3 көнгә бер тапкыр чыгарылырга тиеш;
- ауган яисә аврия хәлндәге агачлар булу булу рөхсәт ителми. Авария хәлендәге агач үсентеләре табылган вакыттан алып тәүлек эчендә юкка чыгарылырга тиеш;
- билгесез шәхесләр күмелгән яисә карап тотылмаган каберләр пычрактан һәм чүп-чардан чистартылырга, кабер ташлары куелырга тиеш.
88. Кышкы чорда күмү урыннарын тоту үзенчәлекләре:
- зиратларның үзәк юллары, керү юллары, тротуарлар киңәйтелергә һәм кардан чистартылырга тиеш. Бозы булмаган тигез кар катламы булу рөхсәт ителә;
-үзәк юллар, керү юллары, тротуарлар бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә тиеш. Юллар һәм тротуарлар кар явуга ук эшкәртелергә тиеш;
-беренче чиратта кар чыгару, бозны вату эшләрен үзәк һәм керү юлларында башкару зарур;
- җирләү урыннарының җәяүлеләр зоналарында бозлавыкка каршы материаллар куллану, юллардан чистартылган карны һәм каберләргә, газоннарга, куаклар салу рөхсәт ителми.
89. Җәйге чорда җирләү урыннарын тоту үзенчәлекләре:
- үзәк юллар, подъезд юллары, тротуарлар, каберләр арасында узу һәм җирләү урыннарында гомуми файдаланудагы башка территорияләр төрле пычрактан чистартылырга тиеш;
- яшел үсентеләрне санитар кисү, чүп үләннәрен бетерү буенча чаралары ел саен башкарылырга тиеш.
90. Җирләнгән урынны (крестлар, һәйкәлләр, плитәләр, склеплар һәм башкалар.) карау, чәчәк һәм декоратив куаклар утырту мәрхүмнең яки башка затның законлы вәкиле тарафыннан санитар таләпләрне мәҗбүри үтәү юлы белән башкарыла.

Автотранспорт чараларын озак вакытлы һәм кыска вакытлы саклау урыннарын карап тоту

91. Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау урыннары гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, шулай ук әлеге Кагыйдәләр нигезендә саклау урыннары урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлеге милекчесе (алга таба - хуҗасы) тарафыннан башкарыла.
92. Милекченең бурычлары:
- автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау урыннары территориясенең бөтен периметры буенча койма куярга, ул механик яктан һәм тышкы мохитка карата тотрыклы булырга тиеш;
- коймаларның техник торышын, аларның чисталыгын тикшереп тору, пычрактан, кардан, боздан, мәгълүмати-басма продукциядән вакытында чистартып тору;
- автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау урыннары территорияләрендә һәм алар янындагы территорияләрдә төрле конструкцияләр саклауга юл куймаска;

- автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау урыннары территориясен гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр таләпләренә туры килә торган яктылыкны тигез бүлүне тәэмин итүче тышкы яктырту белән җиһазларга;
- территорияләрендә автомобиль юу һәм ягулык-майлау материаллары кую тыела;
-санитар һәм янгынга каршы кагыйдәләрне үтәү, машина кую урыннары территорияләрен карап тоту.
- машина кую урыннарын даими рәвештә санитар эшкәртеп, чистартып тору, калдыкларны җыю өчен контейнерлар (урналар) кую, каты көнкүреш калдыкларын, карны даими чыгаруны тәэмин итү;
- инвалидларның машина кую урыннары территориясенә тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү. Инвалидлар "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә бушлай махсус автотранспорт чараларын кую өчен урыннардан файдаланалар.

Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү

93. Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү дәүләт һәм башка бәйрәмнәр, истәлекле вакыйгалар белән бәйле чаралар үткәрү чорында башкарыла.
Бәйрәмчә бизәлеш дәүләт һәм муниципаль флаглар элү, лозунглар, гирлянда, панно элү, декоратив элементлар һәм композицияләр, стендлар, трибуналар, эстрада урнаштыру, шулай ук бәйрәм иллюминациясе урнаштыруны үз эченә ала.
Бәйрәм бизәлеше элементларын әзерләгәндә һәм урнаштырганда юл хәрәкәте нең техник җайга салу чараларын ватарга, алып куярга һәм аларны күрә алуда комачаулык тудырырга ярамый.

IV. Җирлек территорияләрен чистарту тәртибе, төзекләндерү эшләре исемлеге һәм аларны үтәү, җирлек территориясен җыештыру һәм карап тотуга карата гомуми таләпләр

94. Җирлек территориясен җыештыру һәм карап тоту вакыты:
1) җәйге чорда - 15 апрельдән 14 октябрьгә кадәр;
2) кышкы чорда-15 октябрьдән 14 апрельгә кадәр.
Әлеге срокларга Башкарма комитет тарафыннан һава шартларына бәйле рәвештә төзәтмәләр кертелергә мөмкин.
95.Җирлек территориясен җыештыру вакытында башкарыла торган эшләр:
1) җирлек территориясен карап тоту, җыештыру буенча системалы эшләр башкару;
2) Башкарма комитетның хокукый актлары нигезендә бердәм массакүләм чаралар үткәрү (өмәләр).
96. Җәйге чорда җирлек территориясен җыештыру пычрактан һәм тузаннан саклау максатында юу, су сибү һәм башка эшләр башкарыла:
-ясалма өслекле территорияләрне себерү (коры вакытта су сибү), урам-юл челтәренең яңгыр сулары канализациясе белән җиһазландырылган объектларының һәм башка ясалма капламлы территорияләрне тузан һәм пычрактан чистарту, юу. Юл катламы, мәйданнар, тротуарлар һәм ясалма өслекле башка территорияләрне юу катламның бөтен киңлегендә башкарыла;
- яңгыр сулары канализациясенең рәшәткәсен чистарту;
-бөтен территориядән чүп җыю;
- 1 июньгә кадәр ел саен кече архитектура формаларын, бакча һәм урам җиһазларын, урналар, спорт һәм балалар мәйданчыкларын, коймаларны, бордюрларны буяу;

- файдалану чикләнгән һәм махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләрдән тыш булган гомуми файдаланудагы территорияләрдә даими рәвештә үләнне чабу (үләннәр 15 см дан артык биеклектә булганда) һәм тәүлек эчендә чабылган үләнне җыештыру;
- яфрак коелган вакытта тәүлегенә бер тапкыр коелган яфракларны җыю һәм чыгару;
-юганнан соң бордюр янындагы лотокларны чистарту.
97. Гомуми файдалану территориясен кышкы чорда җыештыру:
-юл өслекләрен һәм тротуарларны кардан, боздан һәм чүп-чардан чистарту;
- тайгак яки бозлавык булганда җәяүлеләр зонасына, баскычларга ком сибү, юл катламнарын бозлавыкка каршы материал белән эшкәртү;
- язгы чорда карны көпшәкләндерү һәм кар суларын агызуны оештыру.
98. Җирлек территориясендә башкарыла торган җыештыру эшләренең технологиясе һәм режимы һава шартларына бәйсез рәвештә транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итәргә тиеш.
99. Кышкы чорда җәяүлеләр тротуарларын, җир өсте кичүләрен, баскычларны чистарту үзенчәлекләре:
- көчле кар яву чорында җәяүлеләр өчен тротуарлар, баскычлар бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртелергә һәм чистартылырга тиеш;
- бозлавыкка каршы материаллар белән беренче чиратта баскычлар эшкәртелә, аннары тротуарлар.
Бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү вакыты тайгак вакыты беленгәннән алып дүрт сәгатьтән дә соң башкарылмаска тиеш;
-пычрак калдыклар һәм химик реагентлар белән пычранмаган карны салу газон яки бу максатлар өчен алдан билгеләнгән урыннарга яшел үсентеләрне саклanганда һәм кар сулары агуны тоткарламаганда рөхсәт ителә.
100. Җирлек территориясендә рөхсәт ителми:
- урамнарда, мәйданнарда, яшел үсентеләр булган участокларда, скверларда, паркларда, газоннарда, пляжларда һәм гомуми файдаланудагы башка территорияләрдә чүп ташлау;
- гамәлдәге законнар нигезендә гомуми файдалану территорияләрендә җирләү урыннарыннан башка җирдә мемориаль корылмалар (истәлекле корылмалар, коймалар) кую;
- җәмәгать транспорты маршрутларының соңгы пунктларында салонны юу, чистарту һәм транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтү;
- биналар һәм корылмалар, һәйкәлләр, мемориаль такталар, агачлар, куаклар, кече архитектура формалары һәм башка төзекләндерү элементларын җимерү һәм зыян китерү, шулай ук аларны үзбелдекле үзгәртеп кору һәм урнаштыру;
- мәгълүмати-басма продукцияне, граффитины җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, стеналарда, баганаларда, коймаларда(киртәләрдә) һәм бу максатлар өчен каралмаган башка объектларда урнаштыру;
- җир кишәрлекләренең чикләреннән һәм (яки) киртәләреннән читтә хәрәкәт итүче милекне саклау;
- сәнәгать товарларын һәм башка сәүдә предметларын тротуарларда, газоннарда, юлларда урнаштыру;
- билгеләнмәгән урыннарда кар өю;

- тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар ярдәмендә юлны һәм тротуарларны үзбелдекле ябып кую.
101. Рөхсәтсез урыннарда калдыклар урнаштырган затлар үз хисабына әлеге территорияне җыештырырга һәм чистартырга, кирәк булганда җир кишәрлеген рекультивацияләргә тиеш. 20 тәүлек эчендә калдыкларны ташлаучы кеше табылмый икән, аларны юкка чыгару әлеге территорияне җыештыру өчен җаваплы оешма өстенә төшә.
102. Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрендә (территорияләрдә) барлыкка килгән рөхсәтсез чүплекләрне бетерү вәкаләтле орган тарафыннан тәэмин ителә.
Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту
103. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын (алга таба - юллар) җыештыру машиналар йөрү өлешен, тротуарларны, туктау урыннарын, җәмәгать транспортын көтү тукталышларын, ясалма юл корылмаларын даими чистарту, кар һәм боздан арындыруны үз эченә ала.
104.Язгы-җәйге чорда юлларны җыештыру юуны, су сибүне, тузганны бетерүне үз эченә ала.
Көзге-кышкы чорда юлларны җыештыру чүп-чардан, кар һәм боздан арындыруны , юлларга ком-тоз катнашмасы сибүне, тротуарларга коры ком сибүне күздә тота.
105. Юл буенда урнашкан чүплекләрне чистарту көненә бер тапкырдан да ким булырга тиеш түгел, ә тукталыш мәйданчыкларында көнгә ике тапкыр башкарыла.
106.Җәмәгать транспортын көтү павильоннары юылган, буялган, рөхсәт ителмәгән мәгълүмати-басма продукциядән, граффитидан чистартылган булырга тиеш. Кышкы чорда кардан чистартылырга тиеш.
107. Юлларның аерым элементларын җәйге чорда җыештыру буенча таләпләр:
- машиналар йөрү өлеше төрле пычранулардан тулысынча чистартылырга һәм бар киңлегенә юылырга тиеш. Хәрәкәтне җайга салу линияләре белән билгеләнгән күченү, резерв полосалары ком һәм вак чүп-чарлардан даими чистартылырга тиеш;
- ике метрлы лоток зоналары комлы һәм пычрак булырга тиеш түгел. Махсус машиналарның эш вакытында юлның ком һәм төрле вак чүп-чар белән пычрану рөхсәт ителә.
- юл кырыйлары зур габаритлы калдыклардан һәм башка чүп-чарлардан чистартылырга тиеш.
108.Юлларны кышкы җыештыру буенча таләпләр:
- кышкы чорда юлларны җыештыру түбәндәгеләрне үз эченә ала:
юл йөрү өлешен кардан һәм боздан чистарту, җәмәгать транспортын көтү тукталышларын себерү, кар өемләү һәм чыгару;
109. Рөхсәт ителми:
- тротуарларга, юллар һәм аларның машиналар йөри торган өлешенә квартал эчендәге юллардан, ишегалды территорияләреннән, предприятие, оешма территорияләреннән, төзелеш мәйданчыкларыннан, сәүдә объектларыннан юл йөрү өлешен җыештыручы зат белән килешү булмаганда һәм 8.00 сәгатьтән соң кар чыгару;
- тротуарларда, җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, паркларда, скверларда, ишегалларында һәм башка җәяүлеләр зоналарында һәм яшел үсентеләр булган территорияләрдә бозлавыкка каршы реагент сыйфатында техник тоз һәм сыек хлорлы кальций куллану;

- билгеләнгән тәртиптә килештерелмәгән урыннарга кар чыгару;
- кар өемнәре ясау:
- юллар һәм урамнар киселешендә бер дәрәҗәдә һәм тимер юл аркылы чыгу урыннары янында өчпочмак зонасында күз күреме зонасында;
- җәмәгать транспортын көтү тукталышына 20 метрдан якынрак җирдә;
-транспорт коймалары яки югары бордюр белән җиһазландырылган юл участокларында;
- тротуарларда;
- якын-тирә территорияләргә керү юлында;
- автомобильнең тәгәрмәчләре белән пычрак һәм балчык чыгару;
-грунт, чүп-чарны, юеш төзелеш материалларын, киселгән агачларны брезент яки юлларны пычратуныбулдырмый торган башка материал белән капламыйча чыгару, шулай ук төзелеш катнашмаларын һәм эретмәләрне (шул исәптән цементлы-комлы эремәне, известь, бетон катнашмаларын) транспортлау.

Ял итү урыннарын,кешеләр күпләп була торган урыннарны төзекләндерү һәм җыештыру һәм санитар яктан карап тоту

110. Ял итү һәм кешеләр күпләп була торган урыннарга түбәндәгеләр керә:
- бистә урманнарында, пляжларда оештырылган мәйданнар, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары;
- актив ял итү һәм тамаша чаралары урыннары-стадионнар, уен комплекслары, сәхнә мәйданчыклары һәм башкалар.;
-сәүдә объектлары территорияләре (ваклап сату базарлары, сәүдә комплекслары, стационар булмаган ваклап сату челтәре объектлары комплекслары), җәмәгать туклануы, социаль-мәдәни билгеләнештәге, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары территорияләре;
- административ һәм иҗтимагый биналар, учреждениеләр янындагы территорияләр.

111.Паркларны, скверларны, бульварларны, яр буйларын һәм гомуми файдаланудагы башка территорияләрне җыештыру:
- кышкы чорда паркларда, бакчаларында, скверларда, бульварларда һәм башка ял итү зоналарында юлларны чистартканда, яшел үсентеләрнең сакланышы һәм кар суларының китүен тәэмин иткән очракларда, алдан ук шушы максатлар өчен билгеләнгән урыннарга вакытлыча кар туплау рөхсәт ителә.

112. Ваклап сату базарларын җыештыру һәм санитар карап тоту:
- ваклап сату базарлары территорияләре (алга таба - базар) төзекләндерелергә, бәдрәфләр, хуҗалык һәм контейнер мәйданчыклары, контейнерлар һәм урналар белән җиһазландырылырга, каты өслекле һәм яңгыр һәм кар сулары агу урыны, шулай ук суүткәргечләр һәм канализация булырга тиеш;
- базар территориясен төп җыештыру аны япканнан соң башкарыла. Көндез каты көнкүреш калдыклары белән тутырылган чүпҗыйгычларны чистарталар;
- елның җәйге чорында базар территориясендә мәҗбүри рәвештә атна саен юеш җыештыру башкарыла;
- базар территориясе 40 кв. м мәйданда бер урна исәбеннән чүп савытлары белән җиһазландырыла, шул ук вакытта алар арасында прилавка линиясе буйлап ераклык 10 метрдан артмаска тиеш;

113. Базар территориясендә һәм аның янында урнашкан оешмалар, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре, киосклар, сәүдә палаткалары һәм пави-

льоннарының каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төземичә генә эшләве рөхсәт ителми.

114.Сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы урыннарын җыештыру һзм санитар яктан карап тоту:

- сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектлары территорияләрен тулысынча җыештыру тәүлегенә ике тапкырдан да ким башкарылмаска тиеш (иртән һәм кичен). Көндез калдыклар белән тутырылган чүплекләр һәм чүп җыйгычлар чистартыла;
- сәүдә һәм (яки) җәмәгать туклануы объектларына керү юлында икедән дә ким булмаган чүп савыты куела;
- калдыкларны вакытында чыгару тәэмин ителә.

115.Башка сәүдә мәйданчыклары, стационар булмаган ваклап сату челтәре, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар территорияләрен җыештыру елның җылы вакытында алар ябылганнан соң башкарыла. Агымдагы җыештыру көн дәвамында башкарыла. Көндәлек көнкүреш калдыкларын чыгару тәэмин ителә.

116. Халык күпләп була торган һәм ял итү урыннарын төзекләндерү:

- халык күпләп була торган һәм ял итү урыннарын территориясендә төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге каты өслекләрдән, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп-чар өчен урналар һәм контейнерлар, урам техник җиһазлары, яктырту җиһазлары, архитектура-декоратив яктырту җиһазлары, яшелләндерү участокларын саклау элементларын (металл коймалар, махсус каплаулар) үз эченә ала;
- кешеләр күпләп була торган һәм ял итү территорияләрендә, пляжлардан тыш, каты өслекле яки утыртылган үләнле яки яшел үсентеләре булган каты җир булырга тиеш;
- ял итү һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннар территорияләрендә яшелләндерү участокларын чәчәк түтәлләре, газоннар, ялгыз, төркем үсемлекләр, вертикаль, күптяруслы үсемлекләр белән яшелләндерүнең мобиль формалары рәвешендә планлаштырырга кирәк;
- кешеләр күпләп булу һәм ял итү урыннары урнаштыру һәм эшләве тиешле таләпләргә җавап бирә торган бәдрәф кабиналары белән тәэмин ителергә тиеш;
- кешеләр күпләп булу һәм ял итү урыннарындагы фонтан, буалар, елга ярлары, ял итү урыннары пычранган саен чистартылырга тиеш;
-массакүләм чаралар үткәргәндә, аларны оештыручылар чараны үткәрү урынын җыештыруны һәм бозылган җирләрне торгызуны тәэмин итәргә тиеш. Чараны үткәрү урынын җыештыру һәм төзекләндерү эшләрен башкару тәртибе чараны үткәрүгә тиешле рөхсәт алу вакытында билгеләнә.

117. Халык күпләпбула һәм ял итә торган урыннарда рөхсәт ителми:

- билгеләнмәгән урыннарда сәүдә җиһазларын кую һәм саклау;
- территорияне җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату;
- автотранспорт чараларын юу һәм ремонтлау, файдаланылган ягулык-майлау сыеклыкларын агызу;
- автостоянкалар, гаражлар, аттракционнар оештырырга, билгеләнгән тәртипне бозып реклама конструкцияләре урнаштыру;
- газоннар, табигый һәм ясалма яшелләндерү объектларын зарарлау;
- кече архитектура формалары күчерү һәм вату;
- сыек продукт калдыкларын агызу, су, квас һәм сыра цистерналарын тротуарларга, газоннарга һәм юлларга кую;
- автотранспорт чараларының түләүле парковкаларын законсыз оештыру;

- стационар булмаган объектларны үз белдеге белән урнаштырыру;
- тротуарларның асфальт-бетон өслеген, якын-тирә яшел зоналарның һәм территорияләрне төзекләндерүнең башка элементларының бөтенлеген бозу;
- территориядә сәүдә-суыткыч җиһазларын урнаштырыру;
- халыктан каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен идарәче оешмалар белән килешүе булмаганда контейнерлар (бункерлар) кую;
- тимер-бетон блоклар, багана, коймалар, шлагбаумнар кую;
- корылмалар һәм башка җайланмаларның тимер-бетон блоклары, багана, коймалар, шлагбаумнар урнаштыру юлы белән тротуарларны рөхсәтсез каплау;
- сәүдә объектыннан читтә товар кую;
- учак кабызырга, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрергә, мангалларны һәм ачык ут ярдәмендә ризык эшкәртү өчен башка җайланмалар кулланырга.

Күпфатирлы йортның йорт яны территориясен җыештыру, карап тоту һәм төзекләндерү

118. Йорт яны территориясен җыештыру:
- җыештыру түбәндәге тәртиптә үткәрелергә тиеш: тротуарларны, җәяүлеләр юлларын җыештыру(бозлавык һәм тайгак булган очракта - ком сибү), аннары ишегалды территорияләрен җыештыру;
- җыештыру, кар яву вакытында башкарыла торган эшләр (кар чистартудан тыш) 8.00 сәгатькә кадәр бара.
Механикалаштырылган җыештыруны машинаның 4 км/сәг. Тизлеге белән көндезге вакытта үткәрергә рөхсәт ителә.
119. Җәйге җыештыру:
- йорт яны территорияләрен җәйге җыештыру: себерү, юу яки кулдан яисә машинадан су сибү иртәнге сәгатьләрдә яисә кич соңрак вакытта үтәлергә тиеш;
- тротуарларны юуны аның ачык өлешләрен юу рәвешендә биналардан йөрү юлларына таба юнәлдереп башкарырга кирәк;
- көннең эссе вакытында тротуарларны су сибү зарурлык буенча башкарылырга, тәүлегенә ике тапкырдан да ким булмаска тиеш.
120. Кышкы җыештыру:
- түбәләрдә җыелган кар җиргә вакытында ташланырга, киң тротуарларда теземнәргә формалашырга тиеш;
- җыештырылган кар тротуарлардан машиналар йөрү өлешендә, ә ишегалларында кар җыю урыннарында тупланырга тиеш;
- квартал эчендәге йөрү юлларыннан чыгарылган карны өемгә салырга яки роторлы кар чистарткычлар ярдәмендә юл кырыена урнаштырырга кирәк;
- 6 метрдан артык киңлектәге тротуарларда, урамнарның машиналар йөри торган өлешеннән газоннар белән аерып алынган урыннарда карны тротуар уртасына таба чыгарырга рөхсәт ителә;
- тротуарларда карны өемнәргә өю кар яву вакытыннан соң алты сәгатьтән дә соңга калмыйча, ә калган территорияләрдә 12 сәгатьтән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш;
- ишегалларыннан җыелган ком-тоз катнашмалары белән пычратылмаган карны яшел зоналар сакланышын һәм кар суларын агызуны тәэмин иткәндә квартал эчендәге юлларда, газоннарда һәм җәяүлеләрнең ирекле хәрәкәтенә һәм

автотранспортның йөрүенә комачауламый торган ирекле территорияләрдә салу рөхсәт ителә;

- тротуарларны һәм квартал эчендәге юлларны кулдан чистартканда кар тулысынча җыелырга тиеш.

- тайгак булса, юл катламнарын ком-тоз катнашмасы белән эшкәртү норма буенча 0,2-0,3 кг/м тәшкил итәргә тиеш;

- бозлы урыннарны чистартканнан соң барлыкка килгән калдыкларны газонга, агачлар астына яисә ачык грунтка эләктермичә күчерергү кирәк.

121. Яз җитү белән башкарыла торган эшләр:

- кар суларын агызу өчен кирәк булган канауларны юдырту һәм чистарту;

- люкларга һәм яңгыр челтәренең кабул итү коеларына системалы рәвештә кар суы кудырту;

- кар эреп беткәннән соң ишегалды территорияләрен чүптән, калган кардан һәм боздан чистарту.

122. Күпфатирлы йортның йорт яны территориясен карап тоту:

- күпфатирлы йортның йорт яны территориясен (алга таба-йорт яны территориясен) карап тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- даими җыештыру;

- күзәтү һәм яңгыр сулары коеларының люкларын һәм рәшәткәләрен, дренаж, лоток, үткәрү торбаларын чистарту һәм ремонтлау;

- инженерлык челтәрләренең күзәтү коеларына, янгын вакытында су белән тәэмин итү
чыганакларына (гидрантларга, сулыкларга һәм тд.) тоткарлыксыз керү мөмкинлеген булдыру;

- каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыклары җыю һәм чыгару;

- гамәлдәге яшел үсентеләрне карау һәм тәрбияләү;

- кече архитектура формаларын карап тоту, агымдагы һәм капиталь ремонт эшләре башкару.

123. Калдыкларның барлык төрләре су үткәрми торган катламлы контейнер мәйданчыкларына куелган контейнерлар һәм бункерларга тиешле нормаларына туры китереп һәм тиешле күләмдә җыелырга тиеш.

124. Күпфатирлы йортларда яшәүче гражданнарның бурычллары:

- йорт яны территорияләрендә чисталык һәм тәртип сакларга;

- каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны йорт яны территорияләрендә урнашкан махсус контейнерларга һәм махсус мәйданчыкларга гына ташларга.

125. Идарәче оешмалар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар урнаштыру, канализациясез биналарда сыек көнкүреш калдыклары өчен җыентыклар урнаштыру;

- расланган график нигезендә каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны чыгару;

- контейнерлар (бункерлар) һәм контейнер мәйданчыклары, аларга керү урыннарын чиста һәм төзек хәлдә тоту;

- подъездларга керү юлларын чүп-чардан арындыру, эскәмияләр урнаштыру һәм аларны вакытында чистарту;

- тайгак участокларны ком - тозлы һәм (яки) бозлавыкка каршы махсус катнашмалар белән эшкәртү;

- яшел үсентеләрне һәм газоннарны саклау һәм карау;

- тышкы яктырту чараларын төзек хәлдә тоту һәм аларны караңгы төшү белән кабызу.
126. Йорт яны территориясендә рөхсәт ителми:
- яфракларны, калдыкларның теләсә нинди төрләрен һәм чүп-чарны яндыру;
- хуҗалык мәйданыннан тыш урыннарда кием-салым, keләмнәр һәм башка предметларны элеп кую;
- контейнер мәйданчыкларына керү юлларын каплау;
- урам һәм юлларның машиналар йөри торган өлешенә, тротуарларга, газоннарга һәм яшел зоналарга контейнерлар (бункерлар) кую;
- билгеләнгән тәртипне бозып, йорт яны территорияләренең коймаларын үзбелдекле урнаштыру;
- үзбелдекле ишегалды корылмалары төзү;
- йорт яны территориясен металл, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары һәм материаллар, шлак, көл һәм башка җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләү;
- чүп-чар һәм калдыклар ташлау, юынтык су түгү;
- автотранспорт чараларын кую өчен түләүле стоянка оештыру;
- тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар, объектлар, корылмалар һәм башка җайланмалар урнаштыру юлы белән квартал эчендәге юлларны рөхсәтсез каплау;
- автомашиналар юу, ягулык һәм майлау материаллары түгү, тормоза һәм двигательләр ремонтлау, тавыш көйләү эшләрен башкару;
-кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган теләсә нинди эшләр башкару;
-сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре, палаткалар, киосклар, лареклар, мини-базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектлары, автомобильләрне, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак-төяк ремонтлау предприятиеләре, автостоянка урнаштыру;
- йорт яны территориясенең ишегалды эчендәге юллары буенча транспортта бару;
- учак кабызу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангалларны һәм ачык ут ярдәмендә ризык эшкәртү өчен башка җайланмалар куллану.
127. Идарәче оешмалар тәэмин итәргә тиешле эшләр:
- яшел зоналарның сакланышы;
- җәй көне коры һава шартларында газон, чәчәк түтәлләре, агачлар һәм куакларга су сибү;
- газоннарны төзелеш материалларын, ком, чүп-чар, кар һәм боздан саклау;
- яңа агачлар һәм куакларны агротехник чаралар билгеләгән тәртиптә килештерелгән проектлар буенча утырту.
128. Йорт яны территориясен төзекләндерү:
- һәр йорт территориясендә булырга тиеш:
- кием-салым, келәмнәр һәм көнкүреш әйберләре элү, кием киптерү өчен хуҗалык мәйданчыгы;
- өлкәннәр өчен ял итү мәйданчыгы;
- балаларның җәйге һәм кышкы ялы өчен кирәкле булган, яшелләндерелгән, кече архитектура формалары булган, кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән уен һәм спорт мәйданчыклары.

129. Территориянең зурлыгы мөмкинлек биргән очракта участок чикләрендә этләрне йөртү өчен мәйданчык урнаштырылырга мөмкин.
130. Йорт подъездлары каршындагы мәйданчыклар, юл йөрү һәм җәяүлеләр юллары каты өслекле булырга тиеш. Каты өслек урнаштырганда кар һәм яңгыр сулары агу мөмкинлеге каралырга тиеш.
131. Торак йортларда урнашткан җәмәгать билгеләнешендәге биналарда керү юллары йортның торак өлешеннән изоляцияләнгән булырга тиеш, шул ук вакытта персонал автотранспорты ишегалды территориясеннән читтә урнашырга тиеш.
132. Җәмәгать билгеләнешендәге биналар өчен продукция, материаллар төяү ишегалдының фатирларга керү юллары һәм тәрәзәләре ягыннан булырга тиеш түгел. Төяү эшләрен торак йортларның тәрәзәсез ян ягыннан җир асты тоннельләре яисә ябык дебаркадерлар буенча юл ягыннан башкарырга кирәк
133. Транспорт чараларын квартал эчендәге территорияләрдә урнаштыру кешеләрнең тоткарлыксыз йөрүен, шулай ук җыештыручы һәм махсус техниканың тоткарлыксыз эшләвен тәэмин итәргә тиеш.
Шәхси торак төзелгән территорияләрне җыештыру
134. Торак йортлар хуҗалары көн саен җирләрен (шул исәптән кардан) чистарталар.
135. Рөхсәт ителми:
- йорт биләмәсеннән читкә кар чыгару, чүп-чарны ташлау, йорт тирәсеннән читтә сыек көнкүреш калдыклары агызу;
- юлларның йөрү өлешенә кар һәм ишегалды территориясеннән чистартылган боз чыгару;
- йорт биләмәләре янында теләсә нинди калдыклар һәм чүп-чар яндыру;
- йорт яны территориясендә үзбелдекле коймалар ясау;
- якын-тирә территорияне металл, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары һәм материаллар, шлак һәм көл һәм башка җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләү;
-юлларны корылмалар һәм башка җайланмаларга тимер-бетон блоклар, багана, коймалар, шлагбаумнар урнаштыру юлы белән үзбелдекле каплау;
- кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган теләсә нинди эшләр башкару.

V. Территорияне төзекләндерү элементларына таләпләр

136. Территорияне төзекләндерүнең проект документлары булу һәм гамәлдәге закон таләпләре нигезендә эшләү территорияне төзекләндерүнең аерылгысыз компоненты санала.
Мәдәни мирас объектларын саклау зоналарында урнашкан территорияне төзекләндерү элементларына проект документлары мәдәни мирас объектларын саклау, куллану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә вәкаләтле органнар белән килештерелә.
Төзекләндерүнең озак вакыт яки даими файдаланылучы стационар элементларын урнаштыру аларны күчереп кую мөмкинлеген булдырмаска тиеш.
137. Төзекләндерү элементларын карап тотуны, аларны торгызу һәм ремонтлау эшләрен дә кертеп, төзекләндерү элементларының хуҗалары башкара.
Яшелләндерү
138. Яшел үсентеләр булу территорияне төзекләндерүнең мәҗбүри элементы булып тора.
Төзекләндерү эшләрен башкарганда яшел үсентеләрне мөмкин кадәр саклап калырга кирәк.

139. Җирлек территориясендә яшелләндерүне ике төрдә кулланылырга мөмкин: стационар - үсемлекләр грунтка утырту һәм мобиль - махсус күчмә савытларга утырту (контейнерлар, вазоннар һ.б.).
Стационар һәм мобиль яшелләндерү архитектура-ландшафт объектларын (газоннар, бакчалар, чәчәк түтәлләре, куаклар һәм агачлар) төзү өчен рельефның табигый һәм ясалма элементларында, түбәләрдә (түбә яшелләндерү), биналарның һәм корылмаларның фасадларында (вертикаль яшелләндерү) кулланалар.
140. Яшелләндерү объектларын карап тоту - яшел үсентеләрне һәм яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерү, зур булмаган деформацияләрне бетерү, шулай ук җәйге һәм кышкы чорда күчмә кече формаларны җыештыру.
141. Яшел үсентеләр хуҗаларының бурычлары:
- яшел үсентеләрнең сакланышын һәм аларны квалификацияле карауны тәэмин итү;
- җәй айларында коры һава шартларында газоннар, чәчәк түтәлләре, агачлар һәм куакларга су сибүне тәэмин итү;
- газоннарның сакланышын һәм бөтенлеген тәэмин итү;
- яшелләндерү объектларында сулыклар булганда аларны чиста тоту һәм аларны 10 елга бер тапкырдан да ким булмаган ешлыкта ныклы чистарту;
142. Яшелләндерелгән территорияләрдә рөхсәт ителми:
- үзләренә хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен билгеләнгән төзелешләрдән тыш, төзелеш эшләре башкару ;
-үзбелдекле агач һәм куак утырту, газоннарны һәм чәчәклекләрне юк итү;
- агачларга һәм башка яшел үсентеләргә гамак, таган, турниклар, кер юу өчен бау, реклама һәм мәгълүмати щитлар һәм табличкалар, реклама һәм башка мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән конструкцияләр, объектларга хәрәкәт итү юнәлешен күрсәтүче билгеләр, афишалар, белдерүләр, агитация материаллары, техник конструкцияләр, юл хәрәкәтендә катнашучыларны мәгълүмати тәэмин итү чаралары элү;
-ел фасылларына карамастан, стационар булмаган объектлар, шулай ук юл сервисы объектлары урнаштыру;
- төзелеш һәм башка материаллар, калдыклар, чүп-чар, бозлавыкка каршы материаллар һәм башка зарарлы матдәләр, шулай ук ком һәм бозлавыкка каршы реагентлар белән пычранган кар, боз булу;
- бакчалар казу;
- йорт хайваннарын газоннарда һәм чәчәк түтәлләрендә йөртү;
- яфракларны, үләнне, ботакларны яндыру, шулай ук аларны лотокларга һәм башка су үткәрү җайланмаларына тутыру;
- чүп-чарны газоннарга ташлау;
- учак кабызу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангалларны һәм ачык ут ярдәмендә ризык эшкәртү өчен башка җайланмалар куллану;
- сок, сумала чыгару өчен агачларны кисү, аларга башка механик җәрәхәтләр ясау;
- яшелләндерү территорияләрендә урнашкан скульптураларны, эскәмияләрне, коймаларны, урналарны, балалар һәм спорт җиһазларын бозу;
- агачларның тамырларын кәүсәсеннән 1,5 метрдан да якынлыкта ачу һәм агачларның муентыкларын җир яки төзелеш калдыклары белән күмү.
Коймалар
143. Киртәләр урнаштыру төзекләндерүнең өстәмә элементы булып тора.

144. Коймалар түбәндәге төрләргә бүленә:
- билгеләнеше буенча (декоратив, саклагыч, аларның берлеге);
- озынлык буенча (кыска-1,0 м, уртача-1,1-1,7 м, озын-1,8-3,0 м);
- материалның төре (металл, тимер-бетон һәм башкалар).);
- күрү дәрәҗәсе буенча (үтә күренмәле , күренми торган);
- стационар дәрәҗәсе (даими, вакытлы, күчмә) һәм башка төрле коймалар.

Коймаларны проектлау аларның урнашу урынына һәм гамәлдәге дәүләт стандартларына, сертификацияләнгән эшләнмәләр каталогларына, индивидуаль проектларга туры китереп башкарыла.

145. Мәдәни мирас объектлары территорияләрен койма белән әйләндереп алу әлеге территорияләр өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә башкарылырга тиеш.

Өслекләрнең капламы

146. Өслекләрне капламы җирлек территориясендә куркынычсыз һәм уңайлы хәрәкәтне тәэмин итә, шулай ук җирлек төзелешенең архитектур йөзен формалаштыра.

Төзекләндерү максатлары өчен түбәндәге капламнар билгеләнгән:
- каты (капиталь) капламнар-монолит яки җыелма капламнар, шул исәптән асфальтлы бетоннан, цементлы бетоннан, табигый ташлардан;
- табигый яки ясалма сибелүчән материалдан (шул исәптән ком, вак таш, керамзит, резина валчыгы) башкарыла торган йомшак (юылмаган) капламнар-табигый халәттә, тыгызланган яки ныгытылган материаллы коры катнашмаларда (шул исәптән ком, вак таш, керамзит, резина валчыгы);
- газон капламнары - үлән капламын әзерләү һәм утырту буенча махсус технологияләр кулланылып эшләнгән каплам;
- катнаш капламнар- капламнарны (рәшәткәле плитка яки газон рәшәткәсе, газонга күмелгән яки йомшак катлам) берләштерүче катнаш капламнар.

147. Каплам төрләрен сайлап алуны аларның максатчан билгеләнеше нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк:
- каты- проектлау вакытында гамәлдә булган янгынга каршы таләпләрне, хәрәкәтнең характерын һәм составын, йөкләнешнең чиген исәпкә алу;
- йомшак -аерым территорияләрне төзекләндергәндә аларның үзенчәлекләрен исәпкә алу (балалар, спорт мәйданчыклары, этләрне йөртү өчен мәйданчыклар, җәяү йөрү юллары);
- экологик яктан аеруча отышлы газон капламы яки катнаш каплам.

Каты төрләренең өслеге тайгак булмаска тиеш (коры вакытта эләктерү үзлеге 0.6, юештә-0,4 коэффициентлы).

Өслекләр

148. Пандуслар, баскычлар, басмалар, борт ташлары өслекләргә керә.

Борт ташлары

149.Борт ташлары тротуар һәм машиналар йөрү өлеше кисешкән урында 150мм дан артык булмаган биеклектә урнаштырылырга һәм ремонт вакытында сакланырга тиеш.

Газоннарга транспорт чараларын кертмәү максатында, ул урыннарда борт ташларын биегрәк итеп урнаштыру рөхсәт ителә.

Газон белән җәяүлеләр юлы кисешкән урыннарда, газоннарны пычрактан һәм чүптән саклау максатыннан, 0.5 м арада 50мм чыгып торучы бакча бортлары ясарга мөмкин.

Җәяүлеләр зоналары территориясендә төрле өслекләрне килештерү өчен табигый материаллардан (кирпеч, агач, керамика) файдаланырга мөмкин.

Баскычлар, басмалар, пандуслар

150. Җәяүлеләр юлының 60 промилледән артык авышлыгы булганда баскычлар урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм башка объектлар урнашкан урыннарда җәяүлеләр юлларында, инвалидлар һәм картлар йортларында авышлык 50 промилледән артык булганда баскычлар һәм пандус ясарга кирәк.

Бордюр пандусының авышлыгы 1:12 кабул ителә.

Төшү һәм күтәрелеш вакытында баскычларның беренче басмаларын ачык контраст буяулар белән аерып чыгарырга кирәк.

Тышкы баскычларның барлык басмалары бер марш чикләрендә баскычларның киңлеге һәм биеклеге буенча бертөрле билгеләнә.

Пандусның киртәләре булмаса, 75 мм биеклектәге киртәле бортик һәм тотынгычлар ясау кирәк.

Юлның горизонталь өлешләре пандус башында һәм ахырында тирә-юньдәге өслек-ләрдән текстура һәм төс белән аерылып тора.

Баскычлар яки пандусларның ике ягы буйлап кул белән ябышу өчен 800-920 мм би-еклектә,стенадан 40 мм ераклыкта, түгәрәк яки турыпочмаклы тотынгычлар ясала.

Мәйданчыклар

151. Җирлек территориясендә түбәндәге мәйданчыклар була: балалар уеннары, өлкәннәр өчен ял итү, спорт белән шөгыльләнү, чүп җыйгычлар урнаштыру, этләрне урамда йөртү һәм өйрәтү, автомобиль кую урыннары мәйданчыклары.

Теркәлгән мәдәни мирас һәйкәлләре һәм аеруча саклаулы табигать территорияләре зоналары чикләрендә мәйданчыклар урнаштыру һәйкәлләрне саклау, табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча вәкаләтле органнар белән килештерелеп башкарыла.

Йорт яны территорияләре, кагыйдә буларак, балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары белән тәэмин ителергә тиеш. Мәйданчыклар төзек һәм имгәнү куркынычы булмаган инвентарь белән җиһазлана.

Балалар мәйданчыгы

152. Балалар мәйданчыгы төрле яшь төркемнәре өчен аерым мәйданчыклар яки яшь мәнфәгатьләренә кагылышлы комплекслы уен мәйданчыклары буларак оештырыла.

Балалар мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала: йомшак өслек төрләре, газонлы мәйданчык өслеген тоташтыру элементлары, яшелләндерү, уен җиһазлары, эскәмияләр һәм урналар, яктырту җиһазлары.

Торак йортлар һәм иҗтимагый биналар тәрәзәләреннән мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәйданчыклары чикләренә кадәр ара 10 метрдан да ким булмаска тиеш, кече һәм урта мәктәп яшендәгеләр өчен - 20 метрдан да ким булмаска тиеш, комплекслы уен мәйданчыклары - 40 метрдан да ким түгел, спорт-уен комплекслары - 100 метрдан да ким урнашмаска тиеш.

Балалар өчен уен мәйданчыклары контейнер мәйданчыкларыннан 20 метрдан да ким урнашмаска тиеш.

153. Балалар мәйданчыкларында:
- җәй көне тигезләү өчен җиргә ком салынырга;
- иртәнге якта себерелергә һәм юешләтелергә;
- мәйданчыкта коймалар һәм корылмаларны буяу елга бер тапкырдан да ким булмаска, ремонт эшләре кирәк булганда башкарылырга тиеш ;
- балалар мәйданчыгы җәяүлеләр хәрәкәтеннән, юллардан, борылу мәйданчыкларыннан, автомобильләр кую урыннарыннан, калдыклар өчен контейнерлар урнаштыру мәйданчыкларыннан, автотранспорт чараларын даими һәм вакытлыча саклау участокларыннан изоляцияләнгән булырга тиеш.

Имгәнүләр булмасын өчен мәйдан территориясендә чыгып торган тамырлы яисә аскы ботаклары салынган агачлар, җир өстенә чыгып торган киселгән җиһазлар (стойкалар, фундаментлар) булмаска тиеш .

Якын-тирә территорияләрне реконструкцияләгәндә балалар мәйданчыклары территориясенә төзелеш материаллары алып бару һәм урнаштыру рөхсәт ителми.

Яктырту җиһазлары мәйданчык урнашкан территориян кагыйдә буларак е яктырту режимында эшләргә тиеш.

Яктырту җиһазларын 2,5 метрдан ким булган биеклектә урнаштыру рөхсәт ителми.

Уен җиһазларын урнаштыру куркынычсызлык нормативларын исәпкә алып башкарылырга тиеш.

154.Балалар мәйданчыкларын карап тоту һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җаваплылык аларны карап тотуны гамәлгә ашыручы затларга йөкләнә.

Спорт мәйданчыклары

155. Спорт мәйданчыклары халыкның барлык яшь төркемнәре өчен дә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен билгеләнгән.

Спорт мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге үз: йомшак яки газон өслеге (җәйге чорда), спорт җиһазлары.

Спорт мәйданчыклары яшелләндерелә һәм койма белән әйләндереп алына. Яшелләндерү мәйданчык периметры буенча башкарыла, вертикаль яшелләндерү кулланырга мөмкин. Койманың биеклеге 2,5-3 м тәшкил итә, мәйданчыклар тоташкан урында-1,2 м дан да ким булмаска тиеш.

Спорт җиһазлары спорт, физкультура мәйданчыкларында яки рекреация составында махсус җиһазландырылган җәяүлеләр кюлларында урнаштырыла. Махсус физкультура снарядлары һәм тренажерлар заводта эшләнгән яисә махсус эшкәртелгән өслекле бүрәнәдән һәм борыслардан эшләнгән булырга мөмкин (ярыклар, кимчелекләр булмау мөһим).

Урнаштыру вакытында сертификацияләнгән җиһазлар каталогларына таянып эш итәргә кирәк.

Ял мәйданчыклары

156. Торак төзелеше территориясендә өлкән буын кешеләренә тыныч ял итү һәм өстәл уеннары өчен билгеләнгән ял мәйданчыклары оештыру мөмкин. Торак йортларның тәрәзәләреннән ял итү мәйданчыклары чикләренә кадәр ара 10 метрдан да ким булмаска, актив өстәл уеннары мәйданчыкларына кадәр - 25 метрдан да ким булмаска тиеш.

Ял мәйданчыгында төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге: каты өслек төрләре, газонлы мәйданчык өслеген тоташтыру элементлары, яшелләндерү, ял итү өчен эскәмияләр һәм өстәлләр, урналар (ким дигәндә, һәр эскәмиягә берәр), яктырту җиһазлары.

Мәйданчыкны каплау плитка түшәү рәвешендә проектларга тәкъдим ителә. Ял итү мәйданчыклары һәм балалар мәйданчыклары бергә булганда балалар уеннары зонасында каты өслек урнаштырылуга юл куярга киңәш ителми.
Парклар территорияләрендә үләндә ял итү өчен мәйданчыклар оештырылырга мөмкин.
Этләр өчен мәйданчыклар
157. Этләрне йөртү өчен мәйданчыклар вәкаләтле органнар белән билгеләнгән тәртиптә килешенгән урыннарда урнаштырыла.
Этләрне урамда йөртү мәйданчыгы территориясендә төзекләндерү элементлары исемлеге: төрле өслек төрләре, коймалар, эскәмияләр, урналар, экскрементларны утильләштерү өчен контейнер, яктырту җайланмалары һәм мәгълүмати җиһазлар. Периметр буенча яшелләндерүне планлаштырырга мөмкин.
Этләрне йөртү өчен мәйданчыклар микрорайонның гомуми файдалану территорияләрендә яшел зоналидан читтәге буш урыннарда, метрополитен линияләренең техник зоналарында һәм гомумҗирлек магистральләрендә, беренче һәм икенче поясларны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар зонасыннан читтә 110 кВт көчәнештән артык булмаган электр тапшыру линияләре астында урнашырга мөмкин.
Торак билгеләнешендәге территорияләрдә урнашкан мәйданчыклар зурлыгы 400-600 кв. м чикләрендә кабул ителә, башка территорияләрдә - 800 кв.м. га кадәр, төзелеш барган очраклард, булган территориаль мөмкинлекләрдән чыгып, мәйданчыкларның зурлыгын киметергә мөмкин.
Мәйданчык чигеннән торак һәм җәмәгать биналары тәрәзәләренә кадәр ара 25 метрдан да ким булмаска тиеш, ә балалар учреждениеләре, мәктәпләр, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыкларына кадәр ара 40 метрдан да ким булмаска тиеш.
Мәйданчык коймасы, кагыйдә буларак, 1,5 метрдан да ким булмаган җиңел металл челтәрдән эшләнә.
Мәйданчык территориясендә файдалану кагыйдәләре язылган мәгълүмати стенд урнаштырылган булырга тиеш.
158. Йорт хайваннарының хуҗалары үз хайваннарының экскрементларын мөстәкыйль рәвештә җыю һәм утильләштерү эшен башкаралар.
Хуҗалары хайваннарның башка хайваннарга һәм кешеләргә куркыныч йогынтысын булдырмый калырга, шулай ук тирә-юньдәгеләр өчен санитар нормалар нигезендә тынычлыкны тәэмин итәргә, гамәлдәге санитар-гигиена һәм ветеринария кагыйдәләрен үтәргә тиеш.
Автомобильләр кую мәйданчыклары
159. Җирлек территориясендә түбәндәге төр мәйданчыклар була ала: автомобильләрне кыска вакытлы һәм озаклап саклау мәйданчыклары .
Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакыт эчендә саклау урыннарында өслек төрләре: коймалар, чүп-чар өчен урналар яки контейнерлар, яктырту җиһазлары, мәгълүмат җиһазлары (күрсәткечләр).
Автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннарына керү юллары җәяүлеләр юлларының төп юнәлешләре белән кисешергә тиеш түгел.
Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау урыны аша җәяүлеләрнең транзит юлларын оештыру рөхсәт ителми.

Автотранспорт чараларын озак вакыт һәм кыска вакытлы саклау урыны калган территориядән киңлеге 3 метрдан да ким булмаган яшел үсентеләр полосасы белән аерылып торырга тиеш.

Кече архитектура формалары

160. Кече архитектура формаларын урнаштыру төзелеш, биналарны һәм корылмаларны реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау проект документлары, шулай ук төзекләндерү яки эскиз тәкъдимнәре проектлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кече архитектура формаларын проектлаганда һәм сайлаганда сертификацияләнгән эшләнмәләр каталогларыннан файдаланырга киңәш ителә. Тарихи урыннар, җирлекнең үзәге, бистәдәге күп функцияле үзәкләр һәм зоналар өчен кече архитектура формалары шәхси проект эшләнмәләре нигезендә башкарылырга тиеш.

161. Кече архитектура формаларына карата төп таләпләр:

- архитектура һәм ландшафт тирәлегенең характерына, территорияне төзекләндерү элементларына туры килү;
- материалларның югары декоратив һәм куланылыш сыйфатлары булу, аларны, тышкы мохит йогынтысын исәпкә алып, озак вакыт дәвамында саклау;
- конструкциянең ныклыгы, ышанычлылыгы, иминлеге.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары

162. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан матур булырга тиеш.

Тышкы мәгълүмат чаралары, оешма турында элмәтакталардан һәм режим турында табличкалардан тыш, вәкаләтле орган белән килештерелгән паспорт нигезендә урнаштырыла.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыручылар аларның торышын күзәтеп торырга, тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын вакытында ремонтларга һәм җыештырырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны аларга реклама яки мәгълүмати хәбәр язмыйча урнаштыру һәм эксплуатацияләү, мәгълүмат кырына зыян китерү, шулай ук тышкы реклама чараларын һәм мәгълүматны полиэтилен пленка һәм башка материаллар белән каплау рөхсәт ителми.

Реклама яки мәгълүмати конструкция хуҗасы территорияне төзекләндерүне һәм (яки) монтаждан (сүтүдән) соң фасадның тышкы кыяфәтен торгызуны өч тәүлек эчендә башкарырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары, аларның фундамент блогы булганда, аның белән бергә сүтелергә тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштырганда корылмаларга зыян китерү, шулай ук аларның бөтенлеген, ныклыгын һәм тотрыклылыгын бетерү рөхсәт ителми.

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:

- дивар конструкциясе;
- декоратив панно;
- консоль конструкциясе;
- түбә конструкциясе;
- витрина конструкциясе;
- оешма элмәтактасы;

- режим турында табличка;
- модульле конструкция;
- стела;
- щит конструкциясе;
- флаглы композиция;
-махсус конструкция.

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларына гомуми таләпләр:

Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларын проектлау, әзерләү һәм урнаштыру Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Россия Федерациясе законнары таләпләренә, аларны саклау һәм куллану таләпләренә туры китереп башкарылырга тиеш.

Тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт теле турындагы закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш.

Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл булырга тиеш.

Гражданнар белдерүләре, мәдәни һәм спорт чаралары турында афиша урнаштыру

163. Белдерүләрне, мәдәни һәм спорт чаралары турында афиша урнаштыру бары тик махсус тумбаларда гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм җәяүлеләр зоналарында билгеләнгән щитларда һәм стендларда гына рөхсәт ителә.

Игъланнар өчен стендлар аерым торучы объектлар рәвешендә яки биналарда яки корылмаларда элмәтакталар рәвешендә урнаштырыла ала.

VI. Коммуникацияләрне төзегәндә, ремонтлаганда, реконструкцияләгәндә җир эшләре башкаруга төп таләпләр

164. Грунтны аеру яки юл катламнарын ачу (җир асты коммуникацияләрен сузу, реконструкцияләү яки ремонтлау, свай һәм шпунтка кадау, электр тапшыру линияләрен, элемтә баганаларын урнаштыру (алмаштыру), яктырту баганалары, грунтны планлаштыру, инженерлык эзләнүләре вакытында һәм башка эшләр) белән бәйле эшләр вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән язма рөхсәт (җир эшләрен башкаруга ордер) булганда гына башкарыла.

165. Җирлек территориясен төзекләндерү белән бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү тәртибе, җир эшләрен башкаруга ордер ясау һәм алу муниципаль хокукый актларның билгеләнгән таләпләре нигезендә башкарыла.

166. Яшел зоналарны бетерергә яки күчереп утыртырга туры килгәндә ул эшләрне Башкарма комитет карары нигезендә башкарырга кирәк.

167. Җирлек юллары буенча хәрәкәтне вакытлыча чикләү яки туктату вәкаләтле орган тарафыннан юлның ике ягында заказчылар һәм эш башкаручылар, эшнең сроклары, карап чыгу мөмкин булган маршрутлар турында кирәкле барлык мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат щитын урнаштыру юлы белән мәҗбүри рәвештә бирелгән рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән щитның рәвеше һәм эчтәлеге рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең тиешле административ регламенты белән билгеләнә.

168. Яраклылык вакыты чыккан ордерлар буенча башкарылганда, җир эшләрен башкару үзбелдекле дип таныла.

VII. Уңайлы мохиткә аерым таләпләр

169. Урамнарны һәм юлларны, мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын проектлаганда өлкән яшьтәге кешеләр һәм инвалидлар өчен уңайлы мохиттән файдалану мөмкинлеген, әлеге объектларны картлар һәм инвалидлар хәрәкәт итә торган элементлар һәм техник чаралар белән тәэмин итүне күздә тотарга тәкъдим ителә.
Өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидлар йөри торган техник чаралар һәм җиһазлар проектлау, төзү, урнаштыруны расланган проект документациясе нигезендә заказчы тарафыннан яңа төзелеш вакытында тормышка ашырырга тәкъдим ителә.

VIII. Йорт хайваннары һәм кошларны карап тоту

170. Йорт хайваннарын һәм кош-кортларны карап тоту өченче затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаска тиеш, йорт хайваннарына һәм кошларына китерелгән зыян өчен җаваплылык гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларның хуҗалары өстендә.
171. Йорт хайваннары хуҗалары үз хайваннарының экскрементларын мөстәкыйль рәвештә җыюны һәм утильләштерүне тәэмин итәләр.
172. Авыл хуҗалыгы терлекләрен (сыер, сарык, кәҗә, дуңгызлар һәм башка) һәм кошларны тоту авыл җирлегендә яшәүчеләргә йорт яны участоклары булган шәхси йорт территориясендә рөхсәт ителә.
173. Барлык продукция бирүче хайваннар (мөгезле эре терлек, кәҗәләр, сарыклар, дуңгызлар, атлар), гражданнарның яшәү урыны буенча ветеринария учреждениеләрендә ел саен яңадан теркәлергә тиеш.
174. Йорт хайваннарын көтү җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнгән көтү урыннарында хуҗасы күзәтүе астында яки аның кушуы буенча башка затның күзәтүе астында рөхсәт ителә.
175. Йорт хайваннарын 7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр урамда йөртү рөхсәт ителә. Башка вакытта урамда һәм торак йортларның ишегалларында тынлыкны тәэмин итү өчен хуҗалар чаралар күрергә тиеш.
176. Этләрне урамда йөртү, өч айга кадәрге эт балаларын һәм кечкенә этләрне йөртү очракларыннан тыш, чылбыр (этне тотып торучы бүтән җайланма), муенчак һәм борынчак кулланып башкарылырга тиеш (әгәр алар махсус сумкада (контейнерда) яки аларны урамда йөртүче зат кулында булмаса). "Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында" 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән эт муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелергә тиеш. Этләрне бәйдән ычкындырып йөртү торак пунктлардан читтә, шулай ук урамда йөрергә рөхсәт итүче билгеләр куелган урыннарда рөхсәт ителә.
177. Хуҗалары йорт хайваннары һәм кошлары тарафыннан тротуарларның, урамнарның, паркларның, газоннарның, балалар мәйданчыклары, скверларның, мәйданнарның, шулай ук торак йортларның подъездларының пычрануына юл куймаска тиеш. Эт, мәчеләр һәм башка вак хайваннарны урамда йөрткәндә, хуҗасы табигый яшәеш калдыкларын тулысынча җыюны тәэмин итә торган кирәк-яраклар булдырырга һәм аны үз вакытында контейнерларга ташларга тиеш.
178. Этне махсус урыннарда гына бәеннән ычкындырырга була. Махсус билгеләнгән мәйданчыклар булмаганда, җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган буш урыннарда йөртү рөхсәт ителә.
179. Этләрне өйрәтү бары тик яхшы итеп әйләндереп алынган мәйданнарда яки җирлек территориясеннән читтә башкарыла ала.

180. Йорт хайваннарын юл буйлап бары тик тәүлекнең якты вакытында һәм юлның уң ягына якынрак итеп куып алып барырга мөмкин. Йорт хайваннарын асфальт түшәлгән юл буенча грунт юллары һәм сукмаклар булмаганда гына йөртергә мөмкин.
181. Урамнарда йорт хайваннарын караучысыз калдырганда, хуҗалары яшел үсентеләрне бозудан килгән зыянны куып кертү өчен киткән чыгымнарны каплый.
182. Йорт кәҗәләре йорт яны территориясенең эчендә генә яки хуҗалары күзәтүе астында көтүлекләрдә асралырга тиеш.
183. Рөхсәт ителми:
- малларны балалар һәм спорт мәйданчыкларында, пляжларда, мәгариф һәм медицина оешмалары территорияләрендә йөртү;
- йорт хайваннарын гражданнарның күпләп ял итү урыннарында урнашкан пляжларда йөртү һәм аларны сулыкларда коендыру;
- тыючы язулар булгандау хайваннарныу чреждениегә кертү;
- торак пунктлар территориясендә хайваннар һәм кошларны караучысыз калдырырга;
- хайваннарның хәрәкәтен контрольдә тота алмаган һәм урамда йөргәндә агрессив тәртибен чикли алмаган затлар, шулай ук яше яки сәламәтлеге аркасында хайваннарның хәрәкәтен контрольдә тота алмаган затлар хайваннарны урамда йөртергә тиеш түгел;
- 14 яшькә җитмәгән затлар тарафыннан этләрен, кечкенә этләрне йөртү очракларыннан тыш, урамда йөртү;
- йорт хайваннарын һәм кошларын балкон, лоджияләрдә, торак йортларның гомуми файдалану урыннарында (чиктәш фатирлар коридорлары, баскыч, чарлак, подвал һәм башка ярдәмче биналарда) даими асрау;
- йорт хайваннарының махсус билгеләнгән урыннадан тыш җирләрдә булуы (чаралар (күргәзмәләр һ.б.) үткәрү урыннарыннан тыш).
184. Йорт хайваннары һәм кош хуҗаларының бурычлары:
-хайван авыруларын кисәтү, терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария таләпләренә җавап бирүен тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймау, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чараларын үткәрү;
- хайваннарның асралу урынын даими контрольдә тоту;
- хайваннар чирләгәндә һәм үлгән, үзләрен сәер тотканда кичекмәстән ветеринария белгечләренә хәбәр итәргә кирәк. Алар килеп җиткәнче авыру хайваннарны башкаларыннан аерып ябу зарур.
- ветеринария белгечләре таләбе буенча диагностика тикшеренүләре үткәрү, саклану прививкалары ясау һәм дәвалау-профилактика эшләре өчен хайваннарны бирергә кирәк.
185. Үлгән терлекләрне күмү махсус билгеләнгән урында махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарыла.
186. Үз территорияләрендә каравылчы этләре булган оешмаларның бурычлары:
- этне гомуми нигезләрдә теркәргә;
- этләрне ныклы бәйдә тотарга;
- килүчеләрнең хайваннар янына үтү мөмкинлеген булдырмаска;
- территориягә кергәндә кисәтү язуы булган очракта этләрне эш беткәннән соң яки гомуми файдаланудагы территориядә генә бәйдән ычкындырырга мөмкин.

187. Җәмәгать урыннарында булган күзәтүчесез хайваннар ауланырга тиеш.
188. Күзәтүчесез хайваннарны аулау җирле үзидарә органнары белән төзелгән килешү буенча махсуслаштырылган предприятие яки башка зат тарафыннан башкарылырга мөмкин.
189. Караучысыз хайваннарны аулау буенча чараларны гамәлгә ашыру хайваннарга карата кешелекле мөнәсәбәт һәм иҗтимагый әхлак нормаларын үтәү принципларына нигезләнә.
190. Рөхсәт ителми:
- суд карарыннан башка фатирлардан һәм шәхси йортлардан хайваннарны тартып алу;
- кибет, даруханәләр, коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре һ.б. янында этләрне бәйдән ычкындыру;
- ветеринар органнар киңәшеннән башка алдавычлар һәм башка аулау чаралары куллану.

IX. Кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту

191. Физик һәм юридик затлар, вазыйфаи затлар җирлек территориясен төзекләндерү буенча әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш.
192. Әлеге кагыйдәләрне бозган өчен административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә (федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган нормаларны һәм кагыйдәләрне үз эченә алган, аларны үтәмәгән өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә җаваплылык билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш) җаваплылыкка тартыла.
193. Төзекләндерү өлкәсендәге закон таләпләрен һәм муниципаль хокукый актларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкка тарту әлеге таләпләрне үтәүдән һәм ясалган җитешсезлекләрне бетерүдән азат итми.